ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27 июнь 2016 ел № 3251

Башкарма комитетның 2016 елның 25 мартындагы 1316 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, «Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2016 елның 29 апрелендәге под.832/16 номерлы приказы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 25 мартындагы 1316 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрне кабул итү һәм аларның көтеп тору урыннарына, шул исәптән Россия Федерациясенең | Гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә, муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, муниципаль хезмәт турында мәгълүмат стендлары урнаштырылган. Бинаның фасад өлешендә муниципаль мәгариф | «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| инвалидларны социаль яклау турындагы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә, андый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга таләпләр | идарәсе органы исеме турында мәгълүмат урнаштырылган.<br>Кабул итүне көтү өчен гариза бирүчеләргә, документлар рәсмиләштерү өчен урындыклар, өстәлләр белән җиһазландырылган урыннар билгеләнгән. Бина санитар кагыйдәләр һәм нормалар нигезендә җиһазландырылган.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү урынына керә алу максатында, инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз килү, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм алардан чыгу, шулай ук объект буенча мөстәкыйль рәвештә хәрәкәтләнү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарга урнаштырыла, шул исәптән мөмкинлекләре чикләнгән инвалидларны да истә тотып. | |

2) 2.16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре | Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>- бинаның җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашы;<br>- кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган бүлмәләр булу;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>- инвалидларның файдалану мөмкинлеге өчен, законда каралган шартлар булу.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләр белән характерлана: | «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | - документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;<br>- муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>- муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан кылынган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын бозуга карата прецедентлар (нигезле шикаятьләр) булу. | |

3) 3.4.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.8. Оешмаларны чираттагы уку елына комплектлаштыру чираттагы уку елына төркемнәрнең һәм аларда буш урыннарның расланган саны нигезендә, агымдагы елның 1 апреленнән 31 августына кадәр гамәлгә ашырыла. Комплектлаштырганда Системада балаларның яше агымдагы елның 31 декабренә исәпләнә.

Уку елы дәвамында тәрбияләнүчеләр Оешмалардан киткән, яңа мәктәпкәчә урыннар гамәлгә кертелгән очракта, Административ регламентның 3.5 пунктында беркетелгән Оешмага җибәрү һәм кабул итү тәртибе нигезендә Оешмаларны комплектлаштыру башкарыла.».

4) 3.4.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.9. Оешмаларны комплектлаштырганда, Системада балаларның яшен исәпләү датасын алмаштыру кирәк булганда, Башкарма комитет тарафыннан Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына үтенечнамә юллана. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән килешенеп, Система администраторы тарафыннан балаларның яшен исәпләү датасын үзгәртү гамәлгә ашырыла торган көнне, өстәмә комплектлаштыру датасы билгеләнә.».

2. Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы В.Х. Харисовка «Интернет» челтәрендә тиешле мәгълүмат системаларында һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыру өчен, әлеге карарны «Мәгълүмати технологияләр үзәге» МАУга бирүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы

В.А. Гаврилов